**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы  муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь  кызының**
**11 нче сыйныф өчен татар әдәбиятыннан**
**ЭШ  ПРОГРАММАСЫ**

**Педсовет утырышында каралды**
**Беркетмә №1  28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку  елы**

**Сыйныф:** *11*
**Укытучы:** *Хәмәтҗанова Фәнүзә Сагировна*

**Сәгатьләр саны:**
**Барлыгы:** *68 сәг.; атнага 2 сәг.*

**Әсәрләрне өйрәнү** *– 58 сәгать*
**Сөйләм үстерү –** *6сәгать*
**Дәрестән тыш уку –** *4 сәгать*

**Планлаштыру** *Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары”( 5-11 нче сыйныфлар/ Ф.Галимуллин, А.Әхмәдуллин. К., “Мәгариф”, 2010) нигезендә төзелде.*

**Дәреслек**: ***Дәреслек:*** *А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Ф.ӘГаниева, Н.Г.Юзиев. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. - Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.*

**Хрестоматия:** *А.Г.Әхмәдуллин, Т.Н.Галиуллин, Н.Г.Юзиев. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен әдәбияттан хрестоматия. – Казан: “Мәгариф”, 2005.*

## Аңлатма язуы

Программа Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законына (2007 нче ел, 1 нче декабрь), ”Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары”на (5-11 нче сыйныфлар), Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына(ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008), МБББУ “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең эш программасы турында нигезләмәсенә, МБББУ “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

### 11 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан урта (тулы) гомуми белем бирүнең максатлары

1. Татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру.
2. Татар әдәбиятының барышын, аның аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән, татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга күнектерү.
4. Текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү.

### Бурычлар

1. Өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзалларга ярдәм итү.
2. Әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, төрен һәм жанрын билгеләргә өйрәтү.
3. Әдәби әсәрне анализлау күнекмәләре булдыру.
4. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне ятлату.
5. Укучыда үз-үзен тәрбияләү күнекмәләре булдыру.
6. Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләре булдыру.
7. Рефератлар, докладлар әзерләргә өйрәтү.
8. Әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинение язу күнекмәләрен үстерү.
9. Әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, сәнгатьнең башка төрләре бергәлегендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият-сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү.
10. Матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау.
11. Укучыда мәктәпне тәмамлап чыккач та матур әдәбият укуга ихтыяҗ булдыру.
12. Әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, поэтикасын аңларлык эстетик зәвык булдыру.

13. Укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләре тәрбияләү.

**Укучыларының белем дәрәҗәсенә таләпләр**

1. Әдәби-тарихи процессның төп закончалыкларын, этапларын, чор әдәбиятына зур өлеш керткән әдипләр иҗатын белү.
2. Мәктәп курсында өйрәнелгән әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә өзлексез барыш итеп күзаллау.
3. Әдәбият тарихы һәм теориясе буенча белемнәргә (тема, проблема, идея, пафос, образлар системасы, сюжет-композиция, телнең сәнгати сурәтләү чаралары, әдәби деталь) нигезләнеп, әдәби әсәрне анализлау һәм шәрехләү.
4. Әсәрне чорга хас әдәби юнәлеш белән бәйлелектә тикшерә һәм аңлата белү.
5. Классик әдипләребезнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белү.
6. Әдәбият теориясенә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, аларның билгеләмәләрен белү (әдәби процесс, иҗат методы, сәнгатьчә алымнар-чаралар, анализ төрләре, язучының стиле, әдәбият һәм чор, шәхес һәм җәмгыять бәйләнешләре).
7. Татар әдәбиятында традицияләр һәм яңару процессы, жанрлар үсеше турында гомуми күзаллау булу.

**Формалаштырылырга тиешле күнекмәләр**

1. Әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау.
2. Өйрәнелгән әсәрләр буенча яки бирелгән тема буенча сочинение яза белү.
3. Тәкъдим ителгән яки укучы үзе сайлаган әсәрләрне (шигырь, проза) яттан сөйләү.
4. Язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү.
5. Татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикереңне белдерә, аларга бәя бирә алу.
6. Дәреслек белән эшләү, конспектлар төзү, белешмә әдәбияттан (төрле сүзлекләрдән, тәнкыйть материалларыннан, фәнни чыганаклардан һ.б.) файдалану күнекмәләре булу.

**Программаның эчтәлеге**

| Тема бүленеше | Барлыгы | Теоретик материал | Әдәби әсәргә анализ | Бәйл. сөйләм үстерү | Дәрестән тыш уку | Темага караган төшенчәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Чит илләрдә татар әдәбияты | 1 | 1 | | | | |
| Гаяз Исхакый иҗаты | 3 | 1 | 1 | 1 | | |
| 30 нчы еллар совет әдәбияты | 3 | 2 | 1 | | | Социалистик реализм. |
| Нәкый Исәнбәт иҗаты | 3 | 1 | 1 | 1 | | Трагедия жанры. Трагик конфликт. |
| 40 – 50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы | 2 | 1 | 1 | | | |
| 40 – 50 нче еллар әдәбияты | 3 | 2 | 1 | | | Социалистик реализм. |
| Муса Җәлил иҗаты | 4 | 1 | 2 | 1 | | Лирика (күңел лирикасы, пейзаж, публицистик, |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | фәлсәфи). |
| Фатих Кәрим иҗаты | 2 | 1 | | | 1 | Лирик шигырь, поэма, баллада, шагыйрьнең гражданлыгы. |
| 50 – 60 нчы еллар әдәбияты | 2 | 1 | 1 | | | Драма, әкият-пьеса, тарихи-биографик, фольклорга нигезләнгән пьеса, героизм, патриотизм. |
| Проза үсеше. Г.Бәширов “Намус” романы | 2 | 1 | 1 | | | Роман төрләре. |
| Хәсән Туфан | 4 | 1 | 3 | | | Лирика (күңел лирикасы, пейзаж, публицистик, фәлсәфи). |
| Әмирхан Еники | 4 | 1 | 2 | | 1 | Повесть, роман чагыштыру. |
| Әдәбиятка яңа иҗат көчләре килү | 3 | 1 | 1 | | 1 | Әсәрнең композицион төзелеше. |
| Нурихан Фәттах | 3 | 1 | 1 | 1 | | Тарихи романнар. Тарихи роман, тарихилык принцибы |
| Аяз Гыйләҗев | 2 | 1 | 1 | | | |
| Мөхәммәт Мәһдиев | 3 | 1 | 2 | | | Тезис. |
| Әхсән Баянов | 3 | 1 | | 1 | 1 | Поэма. Идея. |
| Илдар Юзеев | 2 | 1 | 1 | | | |
| Туфан Миңнуллин | 3 | 1 | 1 | 1 | | Моңсу комедия, аллегория, шартлылык. |
| Хәзерге татар әдәбияты | 2 | 1 | 1 | | | |
| Равил Фәйзуллин | 1 | 1 | | | | Тема. |
| Ринат Харис | 1 | 1 | | | | |
| Проза үсеше. | 3 | 1 | 2 | | | |
| Ринат Мөхәммәдиев | 2 | 1 | 1 | | | Төп образлар, художестволы дөреслек. |
| Хәзерге драматургия | 1 | 1 | | | | |
| Рабит Батулла | 2 | 1 | 1 | | | Кульминацион нокта. |
| Ризван Хәмит | 2 | 1 | 1 | | | Монодрама. |
| Бүгенге татар балалар әдәбияты | 1 | 1 | | | | |
| Гомумиләштереп кабатлау | 1 | | 1 | | | |
| **Барысы** | **68** | **30** | **28** | **6** | **4** | |

**Календарь-тематик план**

| № | Дәреснең темасы | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлеге төрләре | План | Факт |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Чит илләрдә татар әдәбияты. Йосыф Акчура, Хәсән | 1 | Чит илләрдәге татар әдәбиятының торышы турында мәгълүматлы булу. Төп темалар һәм проблемалар, бигрәк тә Туган илне сагыну темасының актуаль булуын белү. | 2.09 | 2.09 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Хәмидулла, Гәүһәр Туганай, Хөсәен Габдүш, Әхнәф Таңгатар, Сания Гыйффәт иҗатлары. | | | | |
| 2 | Г.Исхакыйның эмиграциядәге тормышы. | 1 | Язучының 1917 елгы инкыйлабларга мөнәсәбәте, эмиграциядәге тормышы һәм иҗаты буенча мәгълүматлы булу. Хикәяләре, *«Дулкын эчендә»*, *«Ике ут арасында»*, *«Җан Баевич»* пьесаларының идея-эстетик үзенчәлекләрен, *«Локман хәким»* әкияте, *«Олуг Мөхәммәд»* тарихи драмасындагы төп фикерләрне, тарихи-фәлсәфи эчтәлекнең мөһимлеген, татар әдәбияты өчен яңалыгын аңлау. Тезислар язу. | 5.09 | 5/09 |
| 3 | Г.Исхакыйның “Көз” повесте. | 1 | Төп образларның сурәтләнүендә эчке мәгънәне таба белү. Хәлил образына бәя бирә алу. Милли гадәт-йолаларның йомшаруы яки югалуы кешедәге рухи ныклыкка да тәэсир итүен, кешене рухи таркалуга китерүен, башка милләт вәкиленә чит-ят мохитнең аны һәлакәткә дә китерүе мөмкинлеген әсәр аша аңлау. Повестьта сәнгатьчә детальләрнең роле, символик образлар турында мәгълүматлы булу. | 9.09 | 9.09 |
| 4 | Г.Исхакыйның татар әдәбияты һәм сәнгатендә тоткан урыны. | 1 | Г.Исхакыйның татар әдәбияты һәм сәнгатендә тоткан урыны турында күзаллау булу. тест эшләү. | 12.09 | 12.09 |
| 5 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение* “Кеше үз язмышына үзе хуҗа”. | 1 | Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләренә ия булу. Сочинениедә, үз язмышына үзе хуҗа була алсын өчен, кеше актив булырга, ныклы иманлы булырга тиеш, дигән фикерне чагылдыра алу. сочинение язу. | 16.09 | 16/09 |
| 6 | 30 нчы елларда совет әдәбияты. Чор үзенчәлеге. Проза һәм драматургиянең үсеше. | 1 | Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең әдәби процесста чагылышы турында күзаллау булу. 30 нчы елларда иҗади эзләнүләрнең катлаулы, язучылар язмышының фаҗигале булуын аңлау. Шәхес культы чорындагы репрессияләр һәм язучылар турында мәгълүматлы булу. Әсәрләрдә заман темаларын чагылдыру үзенчәлекләрен белү; идея һәм сәнгатьлелек принципларында вульгар социологизмның өстенлек итүен аңлау. Яңа кеше образын эзләүдә, яңа әхлак нормаларын аңлауда үзенчәлекләрне аңлау. Диннең җәмгыять һәм кешелек тарихындагы урынын бозып күрсәтүне белү. Яңа әхлак, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре үзенчәлекләрен таный белү (Г.Кутуйның “Тапшырылмаган хатлар” әсәре мисалында). Социалистик реализм, аның үзенчәлекләрен белү. | 19.09 | 19/09 |
| 7-8 | 30 нчы елларда поэзия үсеше. | 2 | Иҗтимагый идеалны шигърияткә әверелдерү юлында эзләнүләр турында мәгълүматлы булу. мөстәкыйль эш (тест). | 23.09<br>26.09 | 23/09<br>26/09 |
| 9 | Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 1 | Н.Исәнбәтнең тормыш юлы һәм иҗаты, гыйльми эшчәнлеге турында мәгълүматлы булу. Трагедия жанры, трагик конфликт төшенчәләрен аңлау | 30.09 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10-11 | Н.Исәнбәт ”Идегәй” трагедиясе. | 2 | Трагедиянең кыскача эчтәлеген ача белү, идея-эстетик анализ ясый алу.<br>тестлар эшләү, әдәби викторина. | 3.10<br>7.10 | |
| 12-13 | 40-50 нче еллар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы һәм татар язучылары. | 2 | Бөек Ватан сугышының татар язучылары тормышына һәм иҗатына тәэсирен белү. Ил һәм җәмгыятьнең рухи тормышына сугыш керткән үзгәрешләрдән хәбәрдар булу. Дошманны җиңүгә омтылыш пафосының әдәбиятта аерым жанрлар үсешенә тәэсирен аңлау. Партия Үзәк Комитеты 1944 елның августында кабул иткән карар, аның татар әдәбиятына, сәнгать һәм мәдәнияткә ясаган тискәре тәэсире турында белү. | 10.10<br>14.10 | |
| 14-15 | 40-50 нче еллардагы проза үсеше. | 2 | *Ф. Кәрим, Г. Кутуй, И. Гази, А. Шамов* һ. б. хикәя-повестьлары турында гомуми мәгълүматка ия булу. Хикәя төшенчәсен кабатлау, роман төрләре турында мәгълүматларны тирәнәйтү.<br>тест эшләү. | 17.10<br>21.10 | |
| 16 | 40-50 нче елларда драматургия. | 1 | *Т. Гыйззәт, М. Әмир, Н. Исәнбәт пьесалары* турында гомуми мәгълүматка ия булу. Драма, әкият-пьеса, тарихи-биографик, фольклорга нигезләнгән пьеса, героизм, патриотизм төшенчәләренә аңлатма бирә белү. | 24.10 | |
| 17 | 40-50 нче елларда поэзия. М.Җәлилнең тормышы һәм иҗаты. 20-30 нчы еллар иҗаты. | 1 | М. Җәлилнең тормыш һәм сугышчан юлы турында мәгълүматлы булу. Сугышка кадәрге иҗатын кыскача күзаллау. *«Алтынчәч»* драматик поэмасы турында белү. *«Хат ташучы»* поэмасы белән таныш булу. | 28.10 | |
| 18 | М.Җәлилнең сугыш чоры иҗаты. | 1 | Шагыйрьнең сугыш чоры иҗатында батырлык темасының реаль эчтәлек белән сугарылуы. Кеше хисләренең патриотизм пафосы белән тыгыз үрелеп тасвирлануы. | 7.11 | |
| 19 | **М.Җәлилнең ”Моабит дәфтәрләре”.** | **1** | Ватанны саклау сугышында җаваплылык тойгысының төрле поэтик вариацияләре белән таныш булу. Дошманга нәфрәтнең чагылышын, сагыну, ярату, якыннарга хөрмәт һ. б. кешелек тойгыларының шигырьләрдә лаеклы урын алуын күрә белү. Поэтик алымнар һәм бизәкләрне тану, аларның яңалыгын һәм сәнгатьлелек көчен аңлау.<br>Лиро- эпик жанр (баллада, поэма, сюжетлы шигырь, драматик поэма)турында белешмәләр алу. | 11.11 | |
| 20 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* М.Җәлил шигырьләрен яттан сөйләү.<br>Әдәбиятта һәм сәнгатьтә М. Җәлил образы. | 1 | Әсәрне яттан сөйләү. | 14.11 | |
| 21-22 | Ф.Кәримнең тормышы һәм иҗаты. | 2 | *«Урман тын иде», «Кереш җыр», «Бездә яздыр», «Теләк», «Юл», «Иптәш», «Мин — гуманист», «Исә җил», «...Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Һөҗүм», «Моң һәм көч», «Күл һәм күңел», «Кемне кызганыйм?», «Немец җирендә»* шигырьләрен, *«Гөлсем», «Өмет йолдызы»* поэмаларын, *«Тимер һәм тимерче»* балладасын белү. | 18.11<br>21.11 | |
| 23 | *Класстан тыш уку.* Ф.Кәрим шигырьләре. | 1 | Лирик әсәрләргә анализ ясый белү.<br>бер шигыренә анализ ясарга өйрәнү. | 25.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24 | Татар әдәбияты яңа сыйфат үзгәрешләренә күчеш чорында. 50-60 еллар әдәбиятына күзәтү. | 1 | Илдә булган хәлләр һәм сәяси-иҗтимагый үзгәрешләр һәм аларның әдәбиятта чагылу дәрәҗәсе турында белү, аңлата алу. мөстәкыйль эш. | 28.11 | |
| 25 | 50-60 нчы еллар әдәбияты. Тыныч тормышны сурәтләү юлында. | 1 | 50-60 нчы еллар әдәбиятының төп иҗат көчләрен, аларның әсәрләрендә жанр төрлелеген, сәнгатьлелек ягыннан һәм тематикада яңалыкларны мисаллар ярдәмендә күрсәтә белү | 2.12 | |
| 26-27 | Проза үсеше. Г.Бәширов “Намус” романы. | 2 | Әсәрнең хезмәт кешесендәге рухи байлыкны ачуда, тел-сурәтләү чаралары өлкәсендә уңышларын күрсәтә белү. Әсәрнең тормыш дөреслегенә тугрылык ягыннан кайбер җитешсезлекләрен тану. Роман төрләре. Төшенчәне кабатлау. | 5.12 9.12 | |
| 28 | Х.Туфанның тормышы һәм башлангыч чор иҗаты. | 1 | Әдипнең тормыш юлын, шәхес буларак үзенчәлекле сыйфатларын белү. *«Урал эскизлары», «Бибиев-ләр»* поэмаларындагы төп фикер, сәнгатьчә эшләнеш-ләрендә үзенчәлекләрне белү. хронологик таблица төзү | 12.12 | |
| 29-30 | Х.Туфанның тоткынлык чоры иҗаты. | 2 | Х. Туфанның тоткынлык чорындагы иҗат үзенчәлекләрен белү. Шигырьләрендә моң-зар, хәсрәт-сагыну, фаҗига хис-тойгыларының яңа төсмерләр алуын, күңел төшенкелегенә түгел, яктылыкка, киләчәккә хезмәт итүен, шигъриятенең фәлсәфи тирәнлеген аңлау. | 16.12 19.12 | |
| 31 | Х.Туфанның 60-70 нче еллар иҗаты. **«Иртә төшкән кар» шигыре** | **1** | 60—70 нче елларда Х. Туфан иҗатының төп сыйфатларын белү. Лирик геройның рухи баюын күрә белү. Туфан поэзиясенең әдәбиятыбыз өчен әһәмиятен аңлау. ӘТ – Шигырь строфасы һәм строфика. Авторның татар шигыре строфикасына керткән яңалыгын белү. | 23.12 | |
| 32 | Ә.Еникиның тормышы һәм иҗаты, “Әйтелмәгән васыять әсәре”. **«Төнге тамчылар» хикәясе.** | 1 | Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән таныш булу. *«Әйтелмәгән васыять»* хикәясендәге Акъәби образына салынган идеяне аңлау. Хикәянең сәнгатьчә эшләнешенә, композициясендәге үзенчәлекләргә бәя бирә белү. Ярдәмче образларга салынган вазифаны билгели алу. | 9.01 | |
| 33 | Ә.Еникинең сугыш чоры иҗаты. | 1 | Язучының сугыш елларында иҗат иткән хикәяләрендәге психологик бизәкләр, гади кешенең эчке кичерешләрен дөрес һәм тәэсирле итеп сурәтләү, детальләр төгәллеге турында мәгълүматлы булу. | 13.01 | |
| 34 | Ә.Еникинең повестьлары. | 1 | Тоталитар система шартларында үрчегән кимчелекләрне, аларның кеше рухына зыян салуын, шәхесне зәгыйфьләтүен сурәтләүгә багышланган әсәрләрнең татар әдәбияты тарихында тоткан урынын билгели алу. Повесть геройлары холкындагы үзенчәлекләрне бүгенге көн күзлегеннә чыгып бәяли белү. ӘТ - Повесть, роман (чагыштыру), проблема. | 16.01 | |
| 35 | *Класстан тыш уку*. Ә.Еникинең “Матурлык” хикәясе. | 1 | Ана һәм бала мәхәббәтенең үзенчәлекле чагылдырылуын аңлау. Хикәянең сәнгатьчә эшләнешенә анализ ясый белү | 20.01 | |
| 36 | Әдәбиятка яңа иҗат көчләре килү. Г.Ахуновның тормышы һәм иҗаты. | 1 | Г. Ахунов, Х. Вахит, Ш. Галиев, Х. Камал, Ә. Маликов, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев, Т. Миңнуллин, В. Нуруллин, Н. Фәттах, И. Юзеев, М. Хәсәнов һәм башкаларның әсәрләрендә кеше шәхесен гәүдәләндерүдә, кешенең җирдәге урынын ачыклауда яңалык билгеләре, психологизмга игътибар арту турында мәгълүматлы булу; форма | 23.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | өлкәсендә яңалыкларны турында хәбәрдар булу. | | |
| 37-38 | Г.Ахунов “Хәзинә” романы. | 2 | Романның идея-эстетик эчтәлеген белү. Төп образларга бәя бирә алу, аларның сурәтләнешендә үзенчәлекләрне, уңай якларын һәм кимчелекләрен күрсәтә алу. Романның бу чор татар әдәбияты һәм сәнгате өчен әһәмияте.<br>Әсәрнең композицион төзелеше. | 27.01<br>30.01 | |
| 39 | Н.Фәттахның тормышы һәм иҗаты. | 1 | Язучының тәрҗемәи хәле турында белү, иҗаты буенча гомуми күзаллау булу.<br>Тарихи романнар. | 3.02 | |
| 40-41 | Н.Фәттахның “Сызгыра торган уклар” романы. | 2 | Әсәрнең эчтәлеген белү, аның тарихи роман булуын исбатлый алу. Төп образлары, сюжет үстерелеше, характерларның ачылу дәрәҗәсе ягыннан үзенчәлекләрен күрсәтә алу. Борынгы төрки халыклар тарихының бүгенге укучыга тәэсир итәрлек якларын табып күрсәтү, милли колоритны чагылдыру ягыннан әһәмиятен аңлау.<br>Тарихи роман, тарихилык принцибы.<br>тест эшләү. | 6.02<br>10.02 | |
| 42 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* Н.Фәттах яки Г.Ахунов иҗаты буенча *сочинение* | 1 | Сочинение язу. | 13.02 | |
| 43 | А.Гыйләҗевның тормышы һәм иҗаты. | 1 | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты буенча мәгълүматлы булу. | 17.02 | |
| 44 | А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә” повесте. | 1 | Әсәрдә уздырылган төп фикерне ачыклый алу, образларга бәя бирә, художество үзенчәлекләрен күрсәтә белү. Повестьның соңгы еллар әдәбияты өчен яңалыгын аңлау.<br>Проблема. | 20.02 | |
| 45 | М.Мәһдиевнең тормышы һәм иҗаты. | 1 | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты буенча мәгълүматлы булу. | 24.02 | |
| 46-47 | М.Мәһдиевнең **“Кеше китә - җыры кала”** повесте. | 2 | Әсәрнең сәнгатьчә үзенчәлекләрен (сурәтләүдә күпбизәклелек, «тартмалы композиция» принцибына корылган булу, аның уңай һәм кайбер кимчелекле яклары) белү. Стиль үзенчәлекләрен күрә алу.<br>Әдәбиятның иҗтимагый вазифасы (тирәнәйтү). | 27.02<br>3/03 | |
| 48 | Ә.Баянов “Сәяхәтнамә” поэмасы. | 11 | Язучының тормыш юлы һәм иҗаты буенча мәгълүматлы булу.<br>Поэманы анализлый белү. Әдипнең кеше һәм табигать мөнәсәбәтен фәлсәфи тирәнлек белән сурәтләвен, табигатьне саклау мәсьәләләрен үткен итеп куюын аңлау.<br>поэма. | 6.03 | |
| 49 | *Класстан тыш уку.* Ә.Баянов “Тау ягы повесте”. **Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» повесте.** | 1 | Әсәргә мөстәкыйль рәвештә анализ ясый алу.<br>Идея. | 10.03 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 50 | И.Юзеевның тормышы һәм иҗаты. “Өчәү чыктык ерак юлга” поэмасы. **И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» драмасы.** | 1 | Әдип иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү. Шагыйрь һәм драматург буларак иҗат эшчәнлеген күзаллау. Поэма, баллада, шигъри трагедияләре турында мәгълүматлы булу. *«Өчәү чыктык ерак юлга...»* поэмасындагы тормышчан проблемаларны күрә, алар турында үз фикерен җиткерә алу. Фазылҗан, Нур һәм «мин» образларының үзенчәлекләрен билгели алу. Кәккүк, юл образына йөкләнгән мәгънәне аңлата белү. Җанлы һәм җансыз табигать образларының (көймә, урман, чабыш атлары) хатирәләрне тергезүдәге ролен аңлау. | 13.03 | |
| 51 | Т.Миңнуллинның тормышы һәм иҗаты. Иҗат үзенчәлекләре. | 1 | Т.Миңнуллин әсәрләрендә яшәешнең әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелүен, буыннар арасындагы рухи бәйләнешнең югалу куркынычын хәбәр итеп чаң сугылуын, киләчәгебез турында борчылуын төрле нюансларда сәнгатьчә сурәтләнүен, шулар аша әдип шәхесен, аның кешелек сыйфатларын, талантын танып-белү. | 17/03 | |
| 52 | Т.Миңнуллин “Әлдермештән Әлмәндәр”. | 1 | Пьесаның төп конфликтын, темасын, проблемасын белү. Персонажларның характер үзенчәлеген һәм авторның аларны гәүдәләндерү, җанландыру, комик һәм шул ук вакытта моңсу-пошынулы ситуацияләр тудыру осталыгын танып-белү. моңсу комедия, аллегория, шартлылык. | | |
| 53 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. Сочинение “Әлмәндәр – ил карты”. | 1 | Бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү күнекмәләренә ия булу. Әлмәндәр образын тудыру алымнарын танып-белү; образга бәя биреп, тормышта үз урынын тапкан кешеләргә соклану, алар белән горурлана белү. | 20.03 | |
| 54 | Хәзерге татар әдәбиятына кереш. **Р.Зәйдулланың «Без очарга әзерләнгән идек...», «Соңару» шигырьләре.** | 1 | Җәмгыятьтәге кискен үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылуын аңлата белү. Әсәрләрдә милли бәйсезлек һәм мөстәкыйльлеккә омтылу авазлары, милләтебез тарихына игътибарның артуын, тарихи һәм табигатьне саклау темаларының активлашуын күзаллау. Бүгенге әдәбиятта шәхес концепциясенең үзенчәлекләрен күрә белү. | 24.03 | |
| 55 | Поэзия балкышы. Гамил Афзал, Н.Арсланов, Ш.Галиев шигырьләре. **Р.Миңнуллинның «Татарларым» поэмасы.** | 1 | Гамил Афзал, Н.Арсланов, Ш.Галиев шигырьләре ярдәмендә хәзерге поэзиядә яңа тема һәм идеяләр калкып чыгуын, аерым жанрларның активлашуын, аерым жанр чикләрен киңәйтергә һәм төрләндерергә омтылулар турында күзаллау булдыру. Шигъри сүзнең эчке куәтен, җегәрен арттыруда уңышлар турында хәбәрдар булу. Поэзиядә халык иҗатындагы, бөтендөнья әдәбияты һәм сәнгатендәге символикадан, шартлы алымнардан файдаланырга омтылышның артуын һәм җанлануын аңлау һәм аңлата белү. | 7.04 | |
| 56 | Р.Фәйзуллин иҗаты. “Гадиләргә гимн”, “Көрәшчеләр” поэмалары. **«Нюанслар илендә» циклы.** | 1 | Әдип иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү (кешенең рухи халәтен, күңел тирбәнешләрен кыска, җыйнак итеп сурәтләүдә шагыйрьнең табыш һәм ачышлары). *«Гадиләргә гимн»*, *«Көрәшчеләр»* поэмаларының идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлата алу. | 10.04 | |
| 57 | Р.Харис иҗаты. **«Тукайның мәхәббәт төшләре» поэмасы.**М.Әгъләмов тормышы, иҗатының үзенчәлекләре. | 1 | Әдипләр иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү.<br>Р.Харис: *«Ат иярләү»*, *«Ант суы»*, *«Җәлилчеләр»* поэмалары, *«Кеше»* ораториясе;<br>М.Әгъләмов: *«Онытма, Европа?..»*, *«Тукайдан хатлар»* поэмалары. | 14.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 58 | Проза жанрының үсеше. Г.Ахунов “Идел кызы “, М.Хәсәнов “Язгы аҗаган”. **М.Кәбировның «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте** | 1 | Проза жанрында җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасын яңача хәл иткән әсәрләр язылу турында белү. Тоталитар системаның шәхесне изүен, физик һәм мораль яктан мәсхәрәләвен, таптавын әдәби әсәрләр мисалында аңлата белү. | 17.04 | |
| 59 | И.Сәләхов, А.Гыйләҗев иҗатлары һәм аларның әсәрләре. | 1 | Тоталитар системаның шәхесне изүен, физик һәм мораль яктан мәсхәрәләвен, таптавын әдәби әсәрләр мисалында аңлата белү.<br>КТ – тест эшләү яки әдәби викторина сорауларына җавап бирү. | 21.04 | |
| 60 | М.Хәбибуллин “Кубрат хан”, Ф.Латыйфи “Хыянәт”. | 1 | Әсәрләрдә гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар, аларны ил мәнфәгатьләре яктылыгында карау, илнең иминлеген, милләт язмышын алга чыгарып тасвирлау үзенчәлекләрен күрә алу. Сюжет җанлылыгы, образлары турында фикер йөртә, тарихи фактларга, мәгънәләргә, сүз-тәгъбирләргә игътибар итә белү.<br>ӘТ - Тарихи роман.<br>КТ – тест эшләү яки әдәби викторина сорауларына җавап бирү. | 24.04 | |
| 61 | *Класстан тыш уку*. Р.Батулла “Сөембикә” романы. **Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» повесте** | 1 | Әсәргә мөстәкыйль рәвештә анализ ясый алу.<br>ӘТ - Тарихи роман.<br>КТ – тест эшләү яки әдәби викторина сорауларына җавап бирү. | **28.04** | |
| 62 | Р.Мөхәммәдиев әсәрләре. | 1 | Әдип иҗаты, тәнкыйть һәм әдәбият фәне өлкәсендәге эшчәнлеге турында гомуми күзаллау булу. *«Кенәри — читлек кошы», «Сират күпере»* романнары буенча мәгълүматлы булу.<br>КТ – тест эшләү яки әдәби викторина сорауларына җавап бирү. | 1.05 | |
| 63 | Р.Мөхәммәдиев “Ак кыялар турында хыял” повесте. | 1 | Повестьның сәнгатьчә үзенчәлекләрен белү. | **5.05** | |
| 64 | Хәзерге драматургия. **Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасы. З.Хәкимнең «Гасыр моңы» драмасы.** | 1 | Хәзерге драматургиядә әхлак проблемаларына игътибарның артуын, татар халкының рухи сәламәтлеге мәсьәләләре чагылуын, шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтен төрле вариантларда сурәтләнүне, җәмгыятьнең бүгенге төзелешендә шәхес үсешенә мөмкинлекләр булмауны торган саен кыюрак күрсәтә башлауны яшь драматурглар *З. Хәким, М. Гыйләҗев, Д. Каюмов, Р. Гыйззәтуллин* пьесаларына нигезләнеп аңлата белү. Жанр төрләрендәге яңалыклар, сәнгатьчә дәреслеккә ирешү чаралары турында хәбәрдар булу. | 8.05 | |
| 65 | Рабит Батулла иҗаты һәм аның үзенчәлекләре. | 1 | Әдип иҗаты турында гомуми мәгълүматларны белү. *«Өчәү юлга чыктык»* драмасы, *«Кичер мине, әнкәй!»* мелодрамасы, аларда заманчалыкның чагылышы турында мәгълүматлы булу. | 12.05 | |
| 66 | Р.Батулланың “Сират күпере” драмасы. | 1 | Әсәргә мөстәкыйль рәвештә анализ ясый алу. Г. Тукай образын гәүдәләндерүдә яңалыклар, сәнгатьчә ачышлар, образлар системасы турында аңлата белү | 15.05 | |
| 67 | Р.Хәмид иҗаты. “Җиде бажа”. | 1 | Әсәргә мөстәкыйль рәвештә анализ ясый алу. Драманың төп фикере, сәнгатьчә үзенчәлекләре, яңа алымнар куллануда табышлар турында аңлата белү. Күгәй, Дая, Дулат, Искәндәр образларына бәя бирә алу. | 19.05 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 68 | Бүгенге татар балалар әдәбияты. Ш.Галиев, Р.Миңнуллин иҗатларына күзәтү. **Н.Гыйматдинованың «Сихерче» повесте.** | **1** | Бүгенге татар балалар әдәбиятындагы төп тема һәм проблемалар турында белү. Сурәтләү объектының мәктәп тормышыннан, пионер оешмаларындагы вакыйгалардан гаилә хәлләренә, бала яки яшүсмернең эчке дөньясына авыша баруын күрә алу.<br>МТК – Балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов иҗаты. | 22.05 | |

**Укыту-методик комплекты**

Дәреслек: Дәреслек: А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Ф.Ә.Ганиева, Н.Г.Юзиев. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. - Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.

Хрестоматия: А.Г.Әхмәдуллин, Т.Н.Галиуллин, Н.Г.Юзиев. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен әдәбияттан хрестоматия. – Казан: “Мәгариф”, 2005.

**Укучылар һәм укытучылар өчен методик кулланмалар**

1. Н.М.Йосыпова. Татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнү өчен ярдәмлек. 7-11. Казан, “Мәгариф- вакыт” нәшрияты, 2017.
2. М.Ш.Җәләлиева.Әдәбиятта тойгы катламнары. Казан,“Мәгариф” нәшрияты, 2005.
3. Х.Миннегулов. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2004.
4. Р.Даутов. Балачак әдипләре. 1, 2, 3нче том. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002, 2004, 2005.
5. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: “Мәгариф”, 2004.
6. Бердәм республика имтиханына әзерләнү өчен ярдәмлек. Татар әдәбияты. – Казан: РИЦ “Школа”, 2008.
7. Олимпиадага әзерләнү өчен ярдәмлек (татар әдәбияты). – Казан: РИЦ “Школа”, 2004.
8. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория.Тарих. – Казан: “Мәгариф”, 2004.
9. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: “Мәгариф”, 2007.
10. Дәрес эшкәртмәләре үрнәкләре. Татар теле һәм әдәбият. I кисәк. – Казан: РИЦ “Школа”, 2005.
11. Шакирҗанова Ә.Б. Татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. - Казан: РИЦ “Школа”, 2004.
12. Гыймадиева Н.Г. Дәрестә һәм дәрестән соң. – Казан: “Яңалиф”, 2004.
13. Каюмова Г.Ф. Татар теле һәм әдәбиятын укыту тәҗрибәсеннән. – Казан: “Яңалиф”, 2003.
14. Ганиева Ф., Яруллина Р., Саттарова А. Татар драматурглары: биобиблиографик белешмәлек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007.
15. Минһаҗева Л.И., Мияссарова И.Х. Татар балалар әдәбияты. – Казан: “Хәтер” (ТаРИХ), 2003.

Электрон әсбаплар

| Әсбап төре | Исеме | Сыйныф |
|---|---|---|
| Мультимедияле программа. | Гаяз Исхакый. Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 7-11 |
| Мультимедияле программа. Effecto studios, 2005. | Габдулла Тукай. Тормыш юлы һәм иҗаты. | 5-11 |
| Комплект - 6 CD | Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия - “Аксу” студиясе, 2008. | 5-11 |

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү буенча “ВАМИН” Фонды. Дисклар коллекциясе. 2009. | Габдулла Тукай. Энциклопедия.<br>1. DVD - Сайланма әсәрләр. Телеспектакль (татар телендә).<br>2. DVD – Тукай. Фильм (татар, рус һәм инглиз телләрендә).<br>3. DVD – Тормышы һәм иҗаты (татар һәм рус телләрендә).<br>4. CD – Шигырьләр. Аудиокитап (татар телендә). | 5-11 |

**Интернет-ресурслар**

1 http:// www.mon.gov/ru РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы
2 http:// www.tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
3 http:// www.edu.kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы
4. http:// tataroved.ru Татар тарихы: төрки- татар дөньясы

Искәрмә: «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең «Укыту предметы, курсы буенча эш программаларының төзелеше һәм тәртибе” турында» 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган(беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә һәм каникул көннәренә туры килү сәбәпле, 11 нче сыйныфта программа сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.